ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22 октябрь 2018 ел** **№730**

2019 елга “Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәяләре нормативларын раслау турында

Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне гамәлгә ашырганда автомобиль транспортыннан нәтиҗәле файдалануны арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында»гы 2010 ел, 5 июль, 545 нче карары нигезендә, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

- 2019 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын ;

- гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне.

2. Ютазы муниципаль районыц финанс-бюджет палатасы гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларына туры китереп финанслауны тәэмин итәргә тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

А.В. Сучков
2-80-12

Ютазы муниципаль районы Башкарма
комитетының 2018 елның 22 октябреннән
№730 карары белән расланды

2019 елга «Ютазы муниципаль районы " муниципаль берәмлеге балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәяләре нормативлары

| Автотраспорт чарасы моделе | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | Бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сум | Автотранспорт чарасының бер чакрым үткән юлына ставка, сум |
| КАВЗ | 114 254 | 36,60 |
| ПАЗ | 114 511 | 36,54 |
| ГАЗ «Газель» | 108 623 | 29,95 |
| УАЗ | 108 170 | 28,64 |
| FIAT | 107 912 | 27,25 |
| Peugeot Boxer | 108 427 | 26,89 |
| Ford Transit | 109 251 | 29,98 |

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018
елның 22 октябреннән булган
№730 карары белән расланды

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакын исәпләү тәртибе турында
Нигезләмә

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының фактик узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3.Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен «Ютазы муниципаль районы " муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларыныц фактик узган юлы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында хисап елы өчен автотранспорт чарасының фактта узган юлы буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. $i$ муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f_m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактик узган юлы, чакрымнар;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын бер автотранспорт чарасында йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, сум;

$M_m$ - m моделье автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе атамасы;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.